**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ "УРМАНДЕЕВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ" МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

**КАРАР**

№ 6 28.10.2023 ел

**"Аксубай муниципаль районы Урмандеево авыл җирлегенең Урмандеево торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»**

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Аксубай муниципаль районы Урмандеево авыл җирлеге Уставының 24 статьясына ярашлы, "Аксубай муниципаль районының Урмандеево авыл җирлеге муниципаль берәмлек башлыгы КАРАРы:

1..Аксубай муниципаль районы Урмандеево авыл җирлегенең Урмандеево авылында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 15 сәгать 00 минутка билгеләргә

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

1) Сез 2024 елда Аксубай муниципаль районы Урмандеево авыл җирлегенең Урмандеево авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, хәрби хезмәттә булучылардан, мобилизацияләнгән затлар һәм аларнын гайлә әгъзаларыннан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә , алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

1) торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (ташлар сатып алу, ташу, юлларны кышкы тоту килешү буенча эш өчен түләү )

2) күрсәтелгән кагыйдәләргә ярашлы рәвештә торак пункт территориясен төзекләндерүне оештыру:

- торак пункт территориясен төзекләндерү (балалар уен мәйданчыгы урнаштыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)

3) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм җирләү урыннарын тоту ремонт , традицион күмү урыннарын төзекләндерү материаллар сатып алу

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Җыеннарны оештыру һәм үткәрү өчен җаваплылыкны Урмандеево авыл җирлеге башкарма комитетына йөкләргә.

4. Әлеге карарны Урмандеево авыл җирлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга. http://aksubaevo.tatar.ru, ТР Аксубай муниципаль районы Урмандеево авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында

5. Әлеге карар кабул ителгән көннән үз көченә керә.

Урмандеево авыл җирлеге башлыгы: В.З.Николаев